# Гыйльманов Хәбибрахман Гыйльман улы.

(12 февраль 1925 – 7 июль 2010).

Хәбибрахман Гыйльманов Ямьле Мишә буенда урнашкан Әт авылында дөньяга килгән. Мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын ата-бабалары кебек, туган якларында иген үстерүдән башлый. Сугыш башлану елларының тыныч тормышын, өмет-хыялларын челпәрәмә китергә, ир-егетләр кулларына корал ала. Бүтәннәргә да нәүбәт җиткәч Хәбибрахманны Апас районына окоп казырга җибәрәләр. Иамрала авылына урнаштыралар һәм танклар үтә алмаслык траншеялар казу буенча кушалар. Аларның киңлеге -5, тирәнлеге 4 метр була. Ул кышны зәһәр суык була. Аяк-кулларын өшетүчеләр дә, үлүчеләр дә була. Апаста Хәбибрахман да кулларын өшетә, җима ямьлеге белән бирешми. Кайткач механизаторлар әзерләү курсларында укый һәм көпчәкле трактор белән Әт, Чупач, Сабай авыллары хуҗалыкларында җир эшкәртә, алдынгылар сафында бара.

Х. Гыйльманов армиягә 1943 елның гыйнварында алынып, Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Кытай чигендәге Шимановск шәһәрендә артиллерия разведчигы сугышчан һөнәрен үзләштерә. Япониянең СССРга һөҗүм итәргә җыенмавы билгеле булгач, Ерак Көнчыгыштагы дивизияләр көнбатышка күчерелә. Х. Гыйльманов хезмәт иткән 348нче артиллерия полкы 1нче Украина фронтын тулыландыра. Курск-Орел чыгынтысындагы сугышлар дошманның тармар ителүе белән тәмамланса да, Германия Украинада яңадан зур көчләр туплый. Алда - Киев. Ике як та хәлиткеч атакага әзерләнә, канкойгыч бәрелеш була. Әтнең курыкмас егете хезмәт иткән полк та һөҗүмнең иң канкойгыч урыннарына кертелә. Дошманның каршылыгын сындырып, Киев шәһәрендә кызыл флаг җилферди башлый. Украинаның көнбатышы азат ителгәч, һөҗүм операцияләре Львов юнәлешендә дәвам итә. Польша өчен барган сугышларда Х. Гыйль-

манов ике тапкыр яралана, дәваланганнан соң кабат үз полкына кайта.

Украина җирләре азат ителсә дә, Карпат буйлары әле һаман да немецлар кулында кала бирә. 141нче гвардия дивизиясенә, башка корпуслар белән бергә, шушы төбәктән дошманны куып чыгару ~~дош-~~ бурычы куела. Фашистлар бу гүзәл һәм бай җирләрне үз кулларыннан ычкындырырга теләмиләр. Әмма совет гаскәрләренең көчле басымы астында чигенергә мәҗбүр булалар. Менә - Чехословакия чиге буендагы Ужгород, Мукачева җирләре. Снаряд-бомбалар шартлавы, пулялар сызгыруы тынып тормый. Х. Тайлыманов әлеге сугышларда „Батырлык өчен" медаленә лаек була. Әмма үзенә яраланып, Макиевка госпиталендә дәваланырга туры килә. Табиблар чирдәшләгән кулны кисәргә дигән нәтиҗәгә киләләр. Ләкин солдат каршы килә, дәвалауларын үтенә.

1945 елның апрелендә Сетка II группа инвалид булып кайткан Х. Тайлымановны Саба МТС ы управляющие Н. Ногманов үзенә чакыртып ала. Шуннан соң фронтовик шактый еллар трактор белән җир эшкәртә, игеннәр үстерешә, төрле эшләр башкара. Ике тапкыр авыл Советы депутаты итеп сайлана. Соңыннан Саба урман хуҗалыгының үз якларындагы 13нче обходында урманчы булып ун ел эшли, күп тапкырлар Мактау грамоталары белән бүләкләнә. „Фидакарь хезмәт өчен" медален лесхоз директоры Кургали Миннеханов үзе таккан

Хәбибрахман Тайлыманов соңгы елларда, ачыни гаилә белән Сабага күчеп килгәч, район янгын частенда каравыл начальнигы булып эшләде. Ак авылы кызы Тәнзилә белән биш бала тәрбияләп үстерделәр. Бүгенге көндә аларның 29 оныгы һәм оныкчыклары бар.